ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

21 август 2025 ел

№ 6139

Башкарма комитетның «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү системасын раслау турында» 2025 елның 14 мартындагы 1980 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәткә түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 17 апрелендәге 241 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы «исеме» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге)» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмати-методик бүлекләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы типик нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 7 апрелендәге под-608/25 номерлы боерыгы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү системасын раслау турында» 2025 елның 14 мартындагы 1980 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «җитәкчеләренең» сүзен «җитәкчесенең» сүзенә алмаштырырга;

2) кушымтада:

- исемдә «җитәкчеләренең» сүзен «җитәкчесенең» сүзенә алмаштырырга;

- 6 пунктта таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база окладының күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яисә «дипломлы белгеч» квалификациясе бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 22 271 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 22 276 |
| Җитәкчеләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Учреждение директоры | - | - | 22 446»; |

- 17 пункт таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 23 320 |
| 2 | 1,0114 | 23 586 |
| 3 | 1,0233 | 23 863 |
| 4 | 1,0346 | 24 127 |
| 5 | 1,0473 | 24 423 |
| 6 | 1,0595 | 24 707 |
| 7 | 1,0728 | 25 017 |

| | | |
|---|---|---|
| 8 | 1,0855 | 25 314 |
| 9 | 1,0983 | 25 612 |
| 10 | 1,1119 | 25 929 |
| 11 | 1,12519 | 26 237 |
| 12 | 1,1393 | 26 568 |
| 13 | 1,1535 | 26 899 |
| 14 | 1,1675 | 27 226 |
| 15 | 1,1823 | 27 573 |
| 16 | 1,1973 | 27 921 |
| 17 | 1,2124 | 28 273 |
| 18 | 1,2280 | 28 637». |

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылган көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов